**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 7 августындагы 3281 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 1 сентябрендәге 2885 номерлы**
**«Ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы «Федераль милектәге су объектларында ясалган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 сентябрендәге 2885 номерлы «Ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карары кушымтасына, 2.7.1 пунктындагы «8)» пунктчасына «(тутырмыйча калдыру, төгәлсезлекләр булу, тулысынча тутырмау яки хаталы тутыру, әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган итеп тутыру)» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**